КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 29 август г.Казань № 918

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясендә мәгълүмат технологияләре һәм югары технологияләр индустриясен сыйфатлы үстерүгә ярдәм итә торган Иннополис шәһәрендә уникаль экосистема төзүгә юнәлдерелгән эшчәнлекнең устав төрләрен гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 3 июль, 535 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 18 август, 745 нче карары белән кертелгән үзшәрешләрне исәпкә алып) расланган Россия Федерациясендә мәгълүмат технологияләре һәм югары технологияләр индустриясен сыйфатлы үстерүгә ярдәм итә торган Иннополис шәһәрендә уникаль экосистема төзүгә юнәлдерелгән эшчәнлекнең устав төрләрен гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алу үткәрү сроклары, заявкаларны кабул итә башлау яки сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән дә иртәрәк була алмаган заявкаларны кабул итү тәмамлану датасы (2022 елда заявкаларны кабул итү тәмамлану срогы сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 календарь көнгә кадәр кыскартылырга мөмкин);»;

15 пунктта:

җиденче абзацта «нәтиҗәсенә ирешү турында» сүзләрен «нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешү турында» сүзләренә алмаштырырга;

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучының, субсидия алучылар белән (дәүләт (муниципаль) унитар

предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүгә ризалыгы (чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә субсидия бирелгәндә);»;

унберенче абзацта «, максатлар» сүзен төшереп калдырырга;

22 пунктның беренче абзацында «нәтиҗәләренә ирешү турында» сүзләрен «нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында» сүзләренә алмаштырырга;

26 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«26. Министрлык субсидия алучы тарафыннан субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары үтәлешен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) тикшерә.

Дәүләт финанс контроле органы Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча гамәлгә ашырыла.»;

27 пунктның икенче абзацында «максатлары,» сүзен төшереп калдырырга;

29 пунктта «максатчан» сүзен төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгълүмат технологияләре, цифрлы икътисад һәм (яки) робототехника өлкәсендә семинарлар, конференцияләр, форумнар, олимпиадалар, интеллектуаль конкурслар һәм башка чаралар оештыруга һәм үткәрүгә бәйле, шулай ук Татарстан Республикасы командаларының әлеге чараларда катнашуын тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 03 июль, 540 нчы карары белән расланган Мәгълүмат технологияләре, цифрлы икътисад һәм (яки) робототехника өлкәсендә семинарлар, конференцияләр, форумнар, олимпиадалар, интеллектуаль конкурслар һәм башка чаралар оештыруга һәм үткәрүгә бәйле, шулай ук Татарстан Республикасы командаларының әлеге чараларда катнашуын тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алу үткәрү сроклары, заявкаларны кабул итә башлау яки сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән

дә иртәрәк була алмаган заявкаларны кабул итү тәмамлану датасы (2022 елда заявкаларны кабул итү тәмамлану срогы сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 календарь көнгә кадәр кыскартылырга мөмкин);»;

15 пунктта:

җиденче абзацта «нәтиҗәсенә ирешү турында» сүзләрен «нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешү турында» сүзләренә алмаштырырга;

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучының, субсидия алучылар белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүгә ризалыгы (чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә субсидия бирелгәндә);»;

уникенче абзацта «, максатлары» сүзен төшереп калдырырга;

19 пунктның беренче абзацында «нәтиҗәләренә ирешү турында» сүзләрен «нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында» сүзләренә алмаштырырга;

23 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23. Министрлык субсидия алучы тарафыннан субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары үтәлешен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) тикшерә.

Дәүләт финанс контроле органы Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча гамәлгә ашырыла.»;

24 пунктның икенче абзацында «максатлары,» сүзен төшереп калдырырга;

26 пунктта «максатчан» сүзен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларның махсуслаштырылган торак урыннарны наемга алу шартнамәләре буенча ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, алар арасындагы затларга бирелә торган торак урыннарга милек хокукын дәүләт теркәвенә алуны рәсмиләштерүгә бәйле чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 27 июль, 660 нчы карары белән расланган Юридик затларның махсуслаштырылган торак урыннарны наемга алу шартнамәләре буенча ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, алар арасындагы затларга бирелә торган

торак урыннарга милек хокукын дәүләт теркәвенә алуны рәсмиләштерүгә бәйле чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алу үткәрү сроклары, заявкаларны кабул итә башлау яки сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән дә иртәрәк була алмаган заявкаларны кабул итү тәмамлану датасы (2022 елда заявкаларны кабул итү тәмамлану срогы сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 календарь көнгә кадәр кыскартылырга мөмкин);»;

20 пунктта:

сигезенче абзацта «, максатлары» сүзен төшереп калдырырга;

тугызынчы абзац үз көчен югалткан дип танырга;

27 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«27. Министрлык субсидия алучы тарафыннан субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары үтәлешен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) тикшерә.

Дәүләт финанс контроле органы Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

Субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешүне мониторинглау килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча гамәлгә ашырыла.»;

28 пунктта «нәтиҗәсенә ирешү турында» сүзләрен «нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешү турында» сүзләренә алмаштырырга;

29 пунктта «максатчан һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына бәяләү эшчәнлегенә бәйле эксперт һәм консультация ярдәме күрсәтүне гамәлгә ашыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 19 декабрь, 1104 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына бәяләү эшчәнлегенә бәйле эксперт һәм консультация ярдәме күрсәтүне гамәлгә ашыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алу үткәрү сроклары, заявкаларны кабул итә башлау яки сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән

дә иртәрәк була алмаган заявкаларны кабул итү тәмамлану датасы (2022 елда заявкаларны кабул итү тәмамлану срогы сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 календарь көнгә кадәр кыскартылырга мөмкин);»;

21 пунктның тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучының, субсидия алучылар белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүгә ризалыгы (чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә субсидия бирелгәндә);»;

33 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«33. Министрлык субсидия алучы тарафыннан субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары үтәлешен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) тикшерә.

Дәүләт финанс контроле органы Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.»;

35 пунктның икенче абзацында «максатлары,» сүзен төшереп калдырырга;

37 пунктта «максатчан» сүзен төшереп калдырырга.

5. 2023 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдә булуын туктатып торырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясендә мәгълүмат технологияләре һәм югары технологияләр индустриясен сыйфатлы үстерүгә ярдәм итә торган Иннополис шәһәрендә уникаль экосистема төзүгә юнәлдерелгән эшчәнлекнең устав төрләрен гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 3 июль, 535 нче карары белән расланган Россия Федерациясендә мәгълүмат технологияләре һәм югары технологияләр индустриясен сыйфатлы үстерүгә ярдәм итә торган Иннополис шәһәрендә уникаль экосистема төзүгә юнәлдерелгән эшчәнлекнең устав төрләрен гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 8 пунктының өченче абзацы һәм 9 пунктының сигезенче абзацы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгълүмат технологияләре, цифрлы икътисад һәм (яки) робототехника өлкәсендә семинарлар, конференцияләр, форумнар, олимпиадалар, интеллектуаль конкурслар һәм башка чаралар оештыруга һәм үткәрүгә бәйле, шулай ук Татарстан Республикасы командаларының әлеге чараларда катнашуын тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен коммерциягә карамаган оешмаларга

Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 03 июль, 540 нчы карары белән расланган Мәгълүмат технологияләре, цифрлы икътисад һәм (яки) робототехника өлкәсендә семинарлар, конференцияләр, форумнар, олимпиадалар, интеллектуаль конкурслар һәм башка чаралар оештыруга һәм үткәрүгә бәйле, шулай ук Татарстан Республикасы командаларының әлеге чараларда катнашуын тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 8 пунктының өченче абзацы һәм 9 пунктының җиденче абзацы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларның махсуслаштырылган торак урыннарны наемга алу шартнамәләре буенча ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, алар арасындагы затларга бирелә торган торак урыннарга милек хокукын дәүләт теркәвенә алуны рәсмиләштерүгә бәйле чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 27 июль, 660 нчы карары белән расланган Юридик затларның махсуслаштырылган торак урыннарны наемга алу шартнамәләре буенча ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, алар арасындагы затларга бирелә торган торак урыннарга милек хокукын дәүләт теркәвенә алуны рәсмиләштерүгә бәйле чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә кушымтаның 9 пунктының өченче абзацы, 11 пунктының икенче абзацы, 3 пунктның 2 пунктчасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына бәяләү эшчәнлегенә бәйле эксперт һәм консультация ярдәме күрсәтүне гамәлгә ашыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 19 декабрь, 1104 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына бәяләү эшчәнлегенә бәйле эксперт һәм консультация ярдәме күрсәтүне гамәлгә ашыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибенең 9 пунктының өченче абзацы һәм 10 пунктының унсигезенче абзацы;

6. Әлеге карар (әлеге карарның 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктының унөченче абзацыннан, 2 пунктының унөченче абзацыннан, 3 пунктның унөченче абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин